КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1276

2025 елга «Карау буенча ярдәмче» хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы турында

«2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтү проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга түбәндәгеләрне билгеләргә:

айга бер алучыга 61 422,0 сум күләмендә «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар;

«Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә финанслауның бер кешегә исәпләнгән нормативы сәгатенә 377,4 сум күләмендә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга «Сиделка» хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы турында» 2023 ел, 06 декабрь, 1563 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин